СОВЕТ АТРЯКЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ӘТРӘКЛЕ
ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлеге Татар Мөшегесе торак пунктында
халык җыены нәтиҗәләре турында

**23.11.2021ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Татар Мөшегесе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертүгә килешәсезме?, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш,- 23.11.2021 елның узган халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыены беркетмәсе төзелде,алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү:

1) Татар Мөшегесе торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, эшләр өчен түләү);

2) Татар Мөшегесе торак пунктында авыл паркы территориясен төзекләндерү (койма төзекләндерү, кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) Татар Мөшегесе торак пунктында юлларны карап тоту (грейдлау, юлларны чистарту, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) Татар Мөшегесе торак пунктында су алу скважинасына тирән насос сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 171 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 100 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 100 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Татар Мөшегесе торак пунктында халык җыены узуын танырга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Татар Мөшегесе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган , 1 һәм 2 группа инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәт итүгә чакырылгандан тыш,2022 елда һәр кешедән 500 сум күләмендә акча каралган һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү:

1) Татар Мөшегесе торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, эшләр өчен түләү);

2) Татар Мөшегесе торак пунктында авыл паркы территориясен төзекләндерү (койма төзекләндерү, кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) Татар Мөшегесе торак пунктында юлларны карап тоту (грейдлау, юлларны чистарту, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

4) Татар Мөшегесе торак пунктында су алу скважинасына тирән насос сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү) кабул ителгән.

3. Әтрәкле авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (https://menzelinsk.tatarstan.ru/atraklinskoye.htm) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлеге башлыгы Р.Ш. Газизҗанов